**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2023елнның 03 октябре 3161 номер

# КАРАР

**Лаеш шәһәренең «Балалар сәнгать мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү Дәүләт учреждениесе исемен үзгәртү турында» 2008 елның 21 гыйнварындагы 27 номерлы башкарма комитет карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү һәм Уставны яңа редакциядә раслау хакында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 4 августындагы 479-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә **карар бирәм**:

1. «Лаеш шәһәренең «Балалар сәнгать мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү дәүләт учреждениесе исемен үзгәртү турында» район Башкарма комитетының 2008 елның 21 гыйнварындагы 27 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә һәм Уставны яңа редакциядә, кушымта нигезендә, бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Г.Карсаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**

*Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2023елның «_» ___ __номерлы карарына кушымта*

«Лаеш шәһәренең «Балалар сәнгать мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү Дәүләт учреждениесе исемен үзгәртү турында» район Башкарма комитетының 2008 елның 21 гыйнварындагы 27 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү һәм Уставны яңа редакциядә бәян итү.

**4 статьяның 4.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

- белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма мөлкәтенә сак карарга, анда чисталык һәм тәртип сакларга;

**4.5. статьяның 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле пункт өстәргә:**

-яшь һәм психофизик үзенчәлекләрне исәпкә алып, белем бирү программасында каралган һәм укучыларда хезмәт сөючәнлек һәм төп хезмәт күнекмәләрен, хезмәт нәтиҗәләренә катнашлык һәм хөрмәт хисләрен формалаштыруга юнәлдерелгән иҗтимагый файдалы хезмәттә катнаштырга.